## ХАЛЫК ҖЫЕНЫ КАРАРЫ

**Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пунктында гражданнар җыены нәтиҗәләре турында**

“17” ноябрь 2024 ел. № 1

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 06.10.2003 ел №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьясы, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 28.07.2004 ел №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә, 2024 елның 17 ноябрендә “Сез 2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниөипаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр баликъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк граңданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, мәхсус хәрби операциядә һәләк булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әхәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләргә юнәлтү белән килешәсезме:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы территориясен чистарту (агачларны һәм куакларны кисү, үләнне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куакларны кисү, үләннәрне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Сәрдә авылының Алмаш, Тургай, Яшеллек урамнарындагы урам юлларын ремонтлау (вак таш сатып алу һәм салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

“ӘЙЕ” “КАРШЫ”

мәсьәләсе буенча халык җыены нәтиҗәләре белән беркетмә төзелде.

Халык җыены нәтиҗәләре турындагы беркетмә нигезендә:

Сайлау хокукына ия булган җыенда катнашучылар исемлегенә 136 (йөз утыз алты) кеше кертелгән, җыенда катнашучылар саны 97(туксан җиде) кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча халык җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:

"Әйе» позициясе өчен халык җыенында катнашучы 97(туксан җиде) кеше тавыш бирде;

«Юк» позициясе өчен җыенда катнашучыларның 0 (ноль) тавыш бирде.

Бәян ителгәннәрдән чыгып, халык җыены карар итте:

1. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыенын - узган дип, халык җыены нәтиҗәләрен – дөрес дип танырга.

2. “2025 елда Татарстан Республикасы Әтнә муниөипаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә торак пункты территориясендә яшәү урыны

буенча теркәлгән һәр баликъ булган кешегә, көндезге уку формасы буенча белем алучы студентлардан, 1 нче төркем инвалидлардан, 80 яшьтән өлкәнрәк граңданнардан, махсус хәрби операциядә катнашучы (катнашкан) затлар һәм аларның гаилә әгъзаларыннан, мәхсус хәрби операциядә һәләк булган (вафат булган) затларның гаилә әгъзаларыннан тыш 500 (биш йөз) сум күләмендә узара салым кертү һәм җыелган акчаларны җирле әхәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча түбәндәге эшләрне хәл итүгә юнәлтергә:

1) торак пункт территориясен төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы территориясен чистарту (агачларны һәм куакларны кисү, үләнне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

2) Ремонт, киртәләр кору, традицион күмү урыннарын төзекләндерү (Югары Сәрдә авылы зираты территориясен чистарту (агач һәм куакларны кисү, үләннәрне чаптыру, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3) торак пункт чикләрендә гомуми файдаланудагы җирле әһәмияткә ия булган автомобиль юлларын төзү, ремонтлау, карап тоту (Югары Сәрдә авылының Алмаш, Тургай, Яшеллек урамнарындагы урам юлларын ремонтлау (вак таш сатып алу һәм салу, эшләр һәм хезмәт күрсәтүләр өчен түләү)).

3. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен авыл җирлегенең мәгълүмат стендларында игълан итәргә.

4. Татарстан Республикасы Әтнә муниципаль районы Югары Сәрдә авыл җирлеге Югары Сәрдә авылында узган халык җыены нәтиҗәләрен Әтнә муниципаль районының Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://atnya.tatarstan.ru. веб-адресы буенча һәм “Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталында” http://pravo.tatarstan.ru веб-адрес буенча урнаштырырга.

Гражданнар җыенында рәислек итүче,
Югары Сәрдә авыл җирлеге башлыгы Хуснутдинов Р.Р.